ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак- Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы
Арча муниципаль районы, 422036

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Sizin.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**«_30_» _сентябрь_ 2016 ел** **№24**

## Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Сеҗе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру | - Югары Масра авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау өчен материаллар сатып алу;<br>- Ташкичү авылында, Курса тимер юл разъезды т. п. да яшел үсентеләрне санитар кисү<br>-каты көнкүреш калдыкларын вакытлыча урнаштыру урыннарын карап тоту, трактор тарафыннан чүп-чарны трактор белән тыгызлау;<br>- Корса тимер юл разъезды т.п., Курса-Почмак авылында чик буе аншлаглары әзерләү һәм урнаштыру. | 8000<br>8000<br>11000<br>12500 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | Иске Муй авылы зираты территориясен төзеклəндерү эшлəрен дəвам итү | 16000 |
| 3 | Җирлекнең җирле əһəмияттəге юлларында арата юл эшчəнлеге | вак таш, торбалар сатып алу, юлларны чокырлар ремонтлау һəм грейдер белəн утрамбовкалау.<br>Сеҗе авылы, Мəктəп ур., 11-14,18-19, Тынычлык ур., 46-48;<br>Ташкичү авылы, Г. Тукай ур., 23-31 Мөрəле авылы, Үзəк ур. 52-64,70-72, Күпер урамы, 13<br>Яңа Чүриле авылы, Мəктəп ур., 12-20<br>п. Починок-удл.Ф. Бикбаева 12-20<br>Курса-Почмак авылы, Яшьлəр ур., 1-6,М. Җəлил ур., 19-30<br>тимер юл разъезды п., тимер юл ур., 23А-34<br>Иске Масра авылы 1 Май урамы арасындагы киселеш, Октябрь урамы 200м<br>Гөберчəк авылы, М. Мəһдиев урамы киселеше 200 м<br>Сикертəн авылы, Үзəк ур., 30-32, Казаклар авылы, Ю. Гагарин ур., 31-38<br>Чума-Елга авылы, З. Гомəров ур., 50-52<br>Торбалар алу Иске Масра авылы, Киров ур., 9<br>Курса-Почмак авылы, М. Җəлил ур., 6;<br>юлларны грейдерлау.<br>Югары Масра авылы<br>- роторлы чапкыч һəм запас частьлəр сатып алу | 30000<br>15600<br>33100<br>18200<br>8300<br>42300<br>26500<br>15600<br>34100<br>19300<br>6900<br>8700<br>5000<br>5000<br>2000<br>19500 |
| 4 | Халыкны су белəн тəэмин итүне оештыру | Казаклар авылында су челтəрлəрен ремонтлау, материаллар сатып алу | 4000 |
| 5 | Аншлаг ясау | авыл җирлегенең исемен һəм Курса тимер юл разъезды т. п. исемен күрсəтеп | 7500<br>5000 |
| | БАРЛЫГЫ | | 349600 |

əйе юк

Экономиялəнгəн очракта, аерым мəсьəлəлəр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгелəнгəн башка мəсьəлəлəрне хəл итүгə акча җибəрергə рөхсəт итəргə.

2. Əлеге карарны Татарстан Республикасы рəсми хокукый мəгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисə Арча муниципаль районының рəсми сайтында һəм гражданнар күплəп җыела торган урыннарда түбəндəге адреслар буенча мəгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Арча районы, Курса-Почмак авылы, Мəктəп урамы, 1,Сикертəн авылы, Үзəк урамы, 14,Сеҗе авылы, Мəктəп урамы, 15

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Гибадуллина Г.М.